| ГЛАВА ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЕДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Лебедино **КАРАР**

**02.11.2021е.** **№5**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлегенең Березовая Грива авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 136 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлегенең Березовая Грива авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 12 ноябренә 10:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Березовая Грива ав., Пушкин ур., 2Б й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Лебедино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю һәм карап тоту;
- балалар мәйданчыгына беседка әзерләү өчен материаллар сатып алу.

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И. Тюкарев**